# НӘНИ РӘССАМ

Төзеде: Әлки төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы Гиниятуллин И.М.



**Графика редакторы PAINTта рәсем ясарга өйрәнү**

## Графика редакторы Paint

Рәсемнәр белән эшләргә ярдәм итүче программаларны *график редакторлар* дип атыйлар.

*Безнең максатыбыз: Paint та  рәсемнәр ясарга, аларны үзгәртергә өйрәнү.*



1. Paint белән танышу.
2. Кисеп алу, күчереп басу операциясе.
4. Бору, әйләндерү операцияләре.
5. Ныгыту



# Графика редакторы Paint


Windows  операцион системасында Paint график редакторы бар. Аның ярдәмендә рәсемнәр ясарга, аларны үзгәртергә мөмкин. Шулай ук, башка программалар белән эшләгәндә дә рәсемнәрне үзгәртергә кирәк булганда Paint редакторы ярдәмгә килә.

# Графика редакторы Paint

Графика редакторы Paint ны **Пуск > Программы > Стандартные > Paint** командасы белән эшләтеп җибәрәләр. Шуннан соң Paintның эш тәрәзәсе ачыла. Ул берничә өлкәдән тора.

Төп өлкә ак төстә. Рәсем шул өлештә ясала.

# Графика редакторы Paint




Төп өлкәдән сул якта ***инструментлар панеле урнашкан***. Ул рәсем ясау өчен кирәк булган инструментларның кнопкаларын үз эченә ала. Инструментны сайлаганда панельнең аскы өлешендә, бу инструментны үзгәртү өчен яңа тәрәзә чыгарга мөмкин.

# Инструментлар панеле

Ирекле урынны билгеләү

Турыпочмаклы урынны билгеләү

Бөтергеч

Урынны буяу

Төсне билгеләү

Масштаб

Карандаш

Кисть

Сиптергеч

Язу

Туры сызу

Кәкре сызу

Турыпочмаклык ясау

Күппочмак сызу


Эллипс ясау

Читләре түгәрәкләнгән дүртпочмак сызу



Инструментны үзгәртү тәрәзәсе


# Графика редакторы Paint




Төп өлкәдән түбәндә ***палитра*** урнаша. Ул төсләрне үз эченә ала. Әгәр кирәк төс палитрада булмаса, аны барлыкка китерергә мөмкин.



# Туры сызык сызу




Туры сызык сызу өчен:


1.Инструментлар наборында  кнопкасын сайлап алабыз.

2. Ярдәмче тәрәзәдә сызыкның калынлыгын билгеләгез.


3. Сызыкның төсен билгеләгез.

4. “Тычкан”ның сул кнопкасына басып башлангыч ноктадан соңгы ноктага кадәр тартабыз.


# Турыпочмаклык сызу





Турыпочмаклык ясау өчен:

1. Инструментлар җыелмасында  кнопкасын сайлагыз.
2. Турыпочмаклыкның төсен сайлагыз.
3. Ярдәмче тәрәзәдә, турыпочмаклыкның эчен буярга кирәк булса, аны үзгәртегез.
4. Курсорны фигура кирәк урынга куеп, “тычкан”ның сул кнопкасына басып төзегез.

# Эллипс һәм әйләнә сызу




## Әйләнә яки эллипс ясау өчен

1. Инструментлар җыелмасында  кнопкасын сайлагыз.
2. Әйләнәнең төсен сайлагыз.
3. Ярдәмче тәрәзәдә, әйләнәнең эчен буярга кирәк булса, аны үзгәртегез.
4. Курсорны әйләнә кирәк урынга куеп, “тычкан”ның сул кнопкасына басып әйләнәне төзегез.

Рәсемне бер урыннан икенче урынга күчерергә, тагын бер шундый ук рәсем кирәк булганда, кабатлап чыгарырга мөмкин. Моның өчен билгеләү, күчерү, кабатлау операцияләреннән файдаланалар. Мәсәлән, бер агач ярдәмендә урман үстерергә мөмкин. Моның өчен бу агачны күбәйтеп басып узеңә ошаган урынга куярга кирәк

# Урман үстер

***Түбәндәге операцияләрне файдалан:***





Өйрәнгәнеңне тикшер

*Билгеләү*


*Күчерү*

*Кабатлау*






# Билгеләү




## Кирәк өлкәне билгеләү өчен:

1. Инструментлар җыелмасында  кнопкасын сайлагыз.
2. Кирәк өлкәне билгеләгез.


# Күчеру




**Билгеләнгән өлкәне күчеру өчен:**

1. “Тычканны” билгеләнгән өлкәгә куярга.
2. Сул кнопкага басып кирәк урынга күчереп куярга.

# Кабатлау




## Билгеләнгән өлкәне кабатлау өчен:

1. “Тычканны” билгеләнгән өлкәгә куярга.
2. Меню>Правка>Копировать> командасын үтәргә.
3. Меню>Правка>Вставить> командасын үтәгәннән соң рәсемне кирәк урынга күчереп куябыз.

# Шарлар бәйләме яса

*Түбәндәге операцияләрне файдалан:*



Ныгыту өчен

Әйләнә


Урынны буяу


Карандаш

Кабатлау

Күчерү







Рәсемнәрне үзгәрткәндә бору, әйләндерү операцияләреннән файдаланырга мөмкин.

Мәсәлән, мазаика төзү өчен бору операциясеннән файдаланалар.

Бору

Мозаиканы төзе








Өйрәнгәнеңне тикшер

# Бору




## Билгеләнгән өлкәне бору өчен:

1. Кирәк өлкәне билгеләргә.
2. Меню>Рисунок> Отобразить/повернуть командасын үтәргә.
3. Килеп чыккан тәрәзәдә кирәк булган бору ысулын сайлап алырга.